**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

_____15.03.2023_________ г. Казань **№_____34од_________**

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге һәркемгә ачык мәгълүматны, шулай ук шулай ук аларны танырга мөмкинлек бирүче мәгълүматны урнаштырган сайтлар һәм (яки) сайт битләре адреслары турында мәгълүматны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъва итүче гражданнар һәм Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге һәркемгә ачык мәгълүматны, шулай ук шулай ук аларны танырга мөмкинлек бирүче мәгълүматны урнаштырган сайтлар һәм (яки) сайт битләре адреслары турында мәгълүматны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерүнең 2017 елның 16 маендагы 01-02/42 номерлы боерык белән расланган тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Форма граждан хезмәткәрләре тарафыннан тутырыла һәм Татарстан Республикасы Электрон Хөкүмәтенең эчке контуры аша бастырып чыгарыла. Граждан хезмәткәрләре яки гражданнар тарафыннан тутырылган Форма Татарстан Республикасы юстиция министры боерыгы белән сайтлар турында мәгълүматларны эшкәртү өчен җаваплы итеп билгеләнгән кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге хезмәткәренә (алга таба - җаваплы зат) бирелә.»

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Җаваплы зат Форманың тулылыгын, «Интернет» челтәрен кулланып анда күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеген тикшерә, шәхси имзасын куя.»;

11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Җаваплы зат «Татарстан Республикасында дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасы муниципаль хезмәте кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында граждан хезмәткәрләренең шәхси карточкаларында сайтлар турында мәгълүматларны тутыруны тикшерә;

тәртипкә кушымтаны үз көчен югалткан дип танырга.

Министр Р.И. Заһидуллин